**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
«5» октябрь 2016 ел

**РЕШЕНИЕ**
№ 37

**Красносельский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында.**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 нче елның 12 нче июнендәге № 67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 нчы статьялары белән, 2004 нче елның 23 нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 нче статьясы, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 14 нче статьясы белән, Красносельский авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 21 нче сентябрендәге 36 нчы номерлы «Референдум үткәрүне оештыру турында» карары нигезендә, Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 нчы елның 21 нче сентябрендәге 58 нче номерлы «Референдум үткәрүне оештыру турында» карары белән, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2016 нчы елның 20 нче ноябренә Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2017 нче елда Красносельский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Красносельский авыл җирлеге территориясендә яктырткычларны һәм урам утларын алыштыру һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес http:/ vysokaya-gora.tatarstan.ru буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р.Никитенко